| | | |
|---|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ<br>КОМИТЕТ КУКМОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА<br>КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**24.11.2022** Кукмара ш. **№ 403**

«Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар гаиләләренә социаль ярдәм күрсәтү чаралары турында» 2022 елның 03 ноябрендәге 381 номерлы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитет җитәкчесе карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнары гаиләләренә ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында» 2022 елның 20 октябрендәге 1122 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 14 ноябрендәге 1213 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә **карар бирәм:**

1. «Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар гаиләләренә социаль ярдәм күрсәтү чаралары турында» 2022 елның 03 ноябрендәге 381 номерлы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитет җитәкчесе карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның гаиләләренә һәм махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (үлгән) гражданнарның гаиләләренә социаль ярдәм чаралары бирү турында»;

1 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар арасыннан махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның, Россия Федерациясе Милли гвардиясендә хезмәт итүче хәрби хезмәткәрләр һәм затлар, Татарстан Республикасында формалашкан «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт үтүче гражданнар, махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны ирекле үтәүче гражданнар, махсус хәрби операция үткәрү зонасына командировкага җибәрелгән Татарстан

Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы, Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе хезмәткәрләренең, шулай ук югарыда күрсәтелгән категориядәге махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (үлгән) гражданнарның гаиләләренә (гаилә әгъзаларына) түбәндәге ярдәм чараларын билгеләргә:»;

3 пунктны үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2022 елның 20 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла, дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында (http://kukmor.tatarstan.ru) урнаштырырга.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **А.Х. Гарифуллин**